


Татар Пишләсе һәм Сузгарье мәктәпләрендә «Үсеш ноктасы» цифрлы һәм гуманитар профильле мәгариф Үзәкләре ачылды. Әйтеп китәргә кирәк, «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында мондый Үзәкләр Мордовиянен 27 мәктәбендә эшли. Безнен мәйданчыкларда «Технология», «Информатика», «ОБЖ» фәннәре буенча гомуми белем бирv программаларын гына тvгел, ә IT-технологияләр, медиатехнологияләр, шахмат белеме, проект һәм дәрестән тыш эшчәнлек буенча остәмә белем бирv программаларын, шулай ук социаль-мәдәни чаралар да гамәлгә ашыру планлаштырыла. «Үсеш ноктасы» проекты чаралары кысаларында без заманча жиһазлар алдык, шул исәптән виртуаль чынбарлык шлемы, квадрокоптерлар, лего – роботлар, яна ноутбуклар, шахмат остәлләре һәм башкалар. Федераль бюджеттан бvлеп бирелгән акчаларнын гомуми суммасы 1 млн. 654 мен сум. Жиһазлар сатып алу белән бергә гадәтләнгән сыйныф бvлмәләрен заманча итеп, бердәм тостә һәм график бизәлештә башкарылган кабинетларга әверелдерv буенча эш алып барылды. «Үсеш нокталары» эшенә безнен инициативалы педагогларыбыз да кертелә, алар дистанцион укытуны узган һәм балаларда уку, фәнни-техник ижат, медиаторлелек, шахмат белеме белән кызыксынуга булышлык итә алалар. Югары тизлекле интернет челтәренә тоташтыру укучыларны дистанцион укытуны оештырырга момкинлек бирәчәк. Коннен беренче яртысында «Үсеш ноктасы» базасында «Технология», «Информатика», «ОБЖ» фәннәре буенча дәресләр




vткәрv кvздә тотыла, ә аннан сон балаларны дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында дәресләр – эшлекле уеннар, тренинглар котә. Монда без компьютерлар белән парталар урнаштырдык, тактаны интерактив панель алыштыра. Шунда ук заманча жиһазлар белән

эш зонасы, шул исәптән виртуаль чынбарлык шлемы, квадрокоптерлар һ.б. урнашкан. Без бу проектны тормышка ашырудан бик күп яна һәм кызыклы нәрсәләр котәбез. Ел ахырында Үзәкнен ни дәрәжәдә файдалы булачагын күрәчәкбез. Сүз дә юк, бу шәһәр һәм авыл мәктәпләре арасында аерма кимүгә ярдәм итәчәк һәм безнен мәктәп укучылары очен сыйфатлы заманча белем бирү момкинлекләрен кинәйтәчәк, балаларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр булдырырга ярдәм итәчәк. Яна белемнәр һәм компетенцияләр үзләштерүдән тыш, коворкинг – балаларга һәм яшүсмерләргә коммуникатив күнекмәләрне, креативлыкны, стратегик һәм пространстволы фикерләүне, стресс ситуацияләрендә психологик тотрыклылыкны камилләштерергә момкинлек бирәчәк. Технология, информатика буенча белем бирү программалары 5-9 сыйныф укучылары очен эшләнгән, әмма проект эшчәнлегенә һәм шахмат белеменә без башлангыч мәктәп укучыларын да җәлеп итәргә планлаштырабыз. Челтәрле элемтә кысаларында без барлык мәктәпләр белән дә эш алып барачакбыз һәм шуна бәйле рәвештә заманча җиһазлардан файдалана алырлык укучылар санын арттырачакбыз, ә бу авыл мәктәпләрендә балаларны һәм педагогларны әзерләү сыйфатын арттырачак. Укучыларыбызга яна момкинлекләр булдырырга - «Үсеш ноктасы» Үзәге очен кабинетларны ремонтлауга район бюджетыннан 495 мен сум бүлеп биргән Рузаевка главасы Вячеслав Юрьевич Кормилицынга рәхмәтләребезне белдерәбез. Спонсорлар ярдәме белән Үзәкнен интерьерын рәсмиләштерергә ярдәм иткән Татар Пишләсе авыл җирлеге башлыгы Ринат Дявлюк улы Шабаевка, ООО «Дуслык» директоры Илдар Сирач улы Овчинниковка, ИП Марат Закир улы Рахмуковка, ИП Эльвира Җәүдәт кызы Туктаровага, ИП Альфия Әхәт кызы Крюковага һәм кабинетларны оформлять итүче Ринат Шәүкәт улы Чумановка зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.

**Флора Шамонова,**
*Татар Пешлэсе мэктэбе директоры*